ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 апрель, 2016 ел № 7/7

Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/12 санлы Карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезнамәгә өстәмәләр кертү хакында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/12 санлы Карары (Шәһәр Советының 2013 елның 20 декабрендәге 22/13, 2015 елның 15 апрелендәге 39/15 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 маддәдә:

- 1.1 пунктында «2008 елның 17 январендәге «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 5-ЗРТ Татарстан Республикасы законы» сүзләрен «2013 елның 25 июнендәге «Муниципаль хезмәт турында» 50-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы Кодексы» сүзләренә алыштырырга;
- 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлар Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль номатив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, аларның мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырырга тиеш.

Күрсәтелгән вазифаларны биләүне дәгъвалаучы затлар үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырырга тиеш.»;

2) 16 маддәнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 9 пунктчаны өстәргә:

«9) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә.»;

3) 19 маддәнең 1 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев